СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №136—137 (7309—7310) | 16 ноябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

***Иртәгә—Авыл хуҗалыгы һәм эшкәрту промышленносте работниклары көне***

## Авыл хуҗалыгы һәм эшкәрту промышленносте работникларына БӘЙРӘМ КОТЛАВЫ!

Безнең хезмәт календарьларында көзнең соңгы ае. Тагын бер крестьян елы артта калды. Йомгак ясарга, сөрүче һәм чәчүче турындагы игелекле рәхмәт сүзләребез белән уртаклашырга, бәйрәм итәргә вакыт җитте. Игенченең, терлекченең, эшкәртүчеләрнең рәсми бәйрәме—авыл хуҗалыгы һәм эшкәрту промышленносте работниклары көне һәм шул ук вакытта халыкның үзе тарафыннан тудырылган, гасырлар тирәнлегеннән килгән бәйрәм көне бу.

Бүген сез, кадерле иптәшләр, бу бәйрәмне җәмгыятебез сәяси һәм икътисади үзгәрешләрдән торган киеренке чор кичергәндә, базар мөнәсәбәтләренә күчү мәлендә билгеләп үтәсез.

Быелгы авыл хуҗалыгы елы катлаулы, мәшәкатьле булды. Базар әлифбасы безнең тарафтан зур кыенлыклар белән үзләштерелә. Авылның материаль-техник тәэмин ителеше бик йомшак хәлдә. Техника, ягулык-майлау материаллары, җиһазлар җитешми. Ләкин профессиональ бәйрәмегезне билгеләп үткәндә бер нәрсәне исегездән чыгармагыз: хезмәт кешесенә кызарырга урын юк. Сезнең игенче хезмәтегезне һәм җирдәге иң бөек һөнәрләрнең берсе булган— икмәк үстерә белүегезне без югары бәялибез.

Районыбыз игенчеләре үстерелгән уңышны үз вакытында һәм югалтуларсыз җыеп алу өчен бөтен көчләрен һәм тырышлыкларын куйдылар. Орлыклык фонд булдырылды, шәһәр халкы бәрәңге һәм яшелчәләр белән тәэмин ителде, терлекләрне нормаль кышлату өчен шартлар тудыру максатында һәртөрле чаралар күрелә, киләчәк елның язгы кыр эшләренә һәрьяклап хәзерлек алып барыла. Моңа, әлбәттә, шәһәрнең хезмәт коллективлары белән ике арадагы эшлекле традицион элемтәләр дә ярдәм итте..

Һәм, әйтергә кирәк: авыл хезмәтчәннәренә инициатива күрсәтү, крестьян зирәклеген эшкә җигү өчен киң мөмкинлекләр бирелгән. Шуңа күрә сез үзегезне җирнең чын хуҗалары итеп көннән-көн ныграк тоясыз. Авылда яңа экономик җитештерү мөнәсәбәтләре раслана. Ирекле конкуренция туа. Аренда коллективларының роле үсә. Районда акрын гына булса да фермерлар сафы ишәя. Шунысы куанычлы, без авылның хуҗаларын булдырырга, туендыручыбызны диктаттан коткарырга омтылабыз. Һәм без сезнең җирне яратуыгызны беләбез, аның турында кайгыртучанлык күрүегезгә, табигатьне саклавыгызга, байлыкларын арттыруга көчегезне кызганмавыгызга ышанабыз.

Бездә резервлар җитәрлек. Әмма һәркемгә үз хезмәт нәтиҗәләрен хуҗаларча тотарга өйрәнергә кирәк әле.

Кадерле иптәшләр! Авыл хуҗалыгы һәм эшкәрту промышленносте работниклары көне —ул барыбызның да бәйрәме. Без сезгә—җирдә эшләүчеләргә сөеп, зур ышану белән карыйбыз. Гаиләдә туендыручы—төп кеше. Үз хезмәтләре белән яшәүче кешеләр булган җәмгыятьтә дә шулай ук. Бәйрәм белән, дуслар! Сезгә хезмәтегездә уңышлар һәм күтәренке күңел юлдаш булсын.

**ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ОКТЯБРЬ РАЙОН СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ.**

## Симертү осталары

Дуңгызчылык автоматкомплексы операторлары арасындагы ярышта икенче звено терлекчеләре алда бара. Алар агымдагы елның ун аенда симертүгә куелган дуңгызларның һәркайсының тәүлеккә уртача 490 грамм артым бирүенә ирештеләр. Ә тулаем артым меңнәрчә центнерлар белән исәпләнә. Мисал өчен звено хезмәт күрсәткән секциядә бүген дә 3226 баш мал симертелә. Аңа кадәр 4270 башын тереләй авырлыгын 105 килограммга җиткереп ит комбинатына озаттылар.

Звено составындагы операторлар Владимир Николаев, Юрий Попов һәм Фәнис Сөнгатуллин технологик циклның тәгәл сакланышын, җиһазларның нормаль эшләвен, малларның катнашазык һәм су белән даими тәэмин ителешен гел күз уңында тоталар. Аларга бу эштә Асия Сабирова, Нина Николаева да һәрьяклап булыша.

Өченче звено операторлары Анатолий Захаров һәм Илфат Әхмәтҗанов та эштә сыната торганнардан түгел. Захаров бирсдә күп еллардан бирле эшли, симертү процессының бар нечкәлекләрен белә. Бер очтан ярдәмче эшчеләр Валентина Маркова, Тәнзилә Сабирова хезмәтенә дә күз-колак: кирәк вакытта булыша. Алар хезмәт күрсәткән линия маллары да тиз үсә ,көнгә һәркайсы 473 грамм артым бирә.

Дуңгыз симертү осталары авыл хуҗалыгы работниклары көнен әнә шулай куанычлы нәтиҗәләр белән каршылыйлар.

**В. БОЙКОВА.**

## ТАБЫННАРГА МУЛ ӨСТӘМӘ

Сәгыйть ага Әхмәдиев пенсиядә инде. Әмма гомере хезмәттә үткән кеше тыныч кына яши алмый, халыктан сөт җыюга алынды һәм вазифасын яшьләргә үрнәк итеп башкара. Яңа Иглайда үзенә беркетелгән участоктагы һәр сыерга 700 килограммнан артык сөт хәзерләде.

Шәһәрнең авыл хуҗалыгы продуктларына ихтыяҗын канәгатьләндерүгә индивидуаль секторның керткән өлеше ел саен арта. Якты Күлдә хәзерләүче вазифасын башкаручы Ибраһим Гыйззәтуллин да шуны гел истә тота, һәркөн сөт җыярга чыга. Авылдашлары моңа күнегеп өлгергән инде, чиләкләре тулы сөт белән каршы алалар. Һәр сыерга җыелган продукция буенча ул Советта иң алда бара.


Ключи поселогында халыкның сөтен сатып алуда Николай Ершов та әйбәт эшли. Якты Күлдән икенче хәзерләүче Ибраһим Шәрипов та үзенә җиткерелгән заданиене арттырып үтәде, бер сыерга 600 килограмм чамасы җыйды.

Индивидуаль сектордан бу төр продукцияне туплау мәсьәләсенә совхоз администрациясе дә даими игътибар бирә. Авылларда тупланган сөтне ташу өчен машина бёркетелгән. Совхоз бу эштә актив катнашучыларга печән, фураж, бөртекле ашлык та бирә.

Кайгыртучанлыкка җавап итеп халык бу төр продукцияне тапшыруда актив катнаша. 1 ноябрьгә авыл Советы буенча һәр сыерга 515 килограмм сөт сатылды.

**В. РӘҖӘПОВ.**

Җир шундый кешеләр барында яшәр, уңыш бирер. Шундый кешеләр барында басуларда игенгә, өстәлләрдә икмәккә кытлык булмас. Андыйларны җир бәхетенә туган диләр. Җир бәхетенә, сезнең белән безнең бәхеткә. Әсгать Баһаветдинович Әхмәтов үзе, бәлки, бу кадәр фәлсәфи фикерләрнең бөтенесе белән килешеп тә бетмәс иде әле. «Ә нәрсә эшләдем соң мин ул кадәр? Ярый, колхозның күптәнге комбайнчысы, ди. Азмы минем кебек 17—18 елын комбайн штурвалы артында үткәргән игенче агайлар? Шундый икмәк үсми, шунсыз дөнья бармый». Әсгать ага бер нәрсәдә хаклы булыр иде: әйе, андый корычлы, егәрле игенчеләр «Комбайн» колхозында, шөкер, аз түгел. Катлаулы елның болай да күп тир түгелгән икмәген җыю өчен таңны да, төнне дә оныттылар алар узган җәйдә. Икмәге үзенә тансык, саламы үзенә кадерле ел икәнен белгәнгә, темпка гына түгел, сыйфатка да зур игътибар булды. Әсгать Баһаветдинович кебек тәҗрибәле игенчеләр сүзе, аларның кырыс таләпчәнлеге моңарчы булмаганча урынлы, мөһим иде бу икмәк өчен көрәштә, ә шәхси үрнәкне —әйтеп тә торасы юк. Әсгать ага соңгысы белән янә үзенең мөхтәрәмлеген ныгытты: ул узган җәй комбайн бункерыннан 3 мең центнер ашлык бушатты. Үзе генә түгел, әлбәттә, ярдәмчесе Илшат Сафиуллин белән. Остаз үз уңышының яртысын һич тайчанмыйча ярдәмче адресына яздыра ала. Булдыклы, уңган егет булып чыкты Илшат. Шуның өстенә 3 нче ел янәшә эшләү аңа остазыннан чын игенче өчен кирәкле күп сыйфатларны үзендә булдырырга булышты, техниканы җентекләп өйрәнде ул. Кем белә, бәлки шул һөнәрен гомерлек юлдаш итәр егет? Җиргә шулай үзенә сыенып, яшьтән хезмәтнең ачысын татып үскән егетләр бик кирәк. Җир шундый кешеләр барында яшәр.



Рәсемдә: «Комбайн» колхозы комбайнчысы Ә. Б. Әхмәтов үзенең ярдәмчесе И. Сафиуллин белән.

## Алда—хезмәт ветераны

**«Москва» колхозы.** Тәҗрибәле терлекче Василиса Васильевна Богданова хезмәтенә сокланмаган кеше юк. «Өлгер дә, җитез дә»,—дип тел шартлаталар аның турында сүз чыккан саен авылдашлары. «Бигрәк эш өчен яратылган инде» дип тә өстиләр. Чыннан да шулай бит. Инде пенсия яшендә булса да Василиса Васильевна һаман яраткан эшен ташларга ашыкмый әле. Алай гына да түгел, яшьләргә үрнәк булырлык эшли. Аның карамагында 54 баш 4 айгача бозау тәрбияләнә, ул алардан 742 шәр грамм тәүлеклек үсеш алуга ирешә. Бу—хуҗалыкта иң әйбәт артым.

Колхозның икенче бригадасы терлекчесе Фәния Кулиева күрсәткечләре дә әйбәт—648 грамм.

**М. СЕМИБРАТОВА,**
бухгалтер.

## *Котлыйбыз!*

«Үрнәк» колхозы идарәсе колхозчыларны авыл хуҗалыгы работниклары көне белән котлый. Ил табынын баетучыларга исәнлек-саулык, гаилә бәхете, уңышлар тели.

# Тынгысызлар

Терлекче хезмәтенең бар авырлыгын Нәҗибулла Гобәйдуллович Әһлиуллиннан да яхшырак белүче бармы икән? Мөгаен, юктыр. 1957 нче елдан бирле тормышын авыл хезмәте белән бәйләгән ул, аның да даимилек, түземлелек сорый торган терлекчелек тармагын сайлаган. Башта дуңгызлар караган, аннан, колхоз бүленеп, дуңгызчылык бетерелгәч, товарлыклы-сөтчелек фермасында терлекче булып эшләгән. Инде Муса Җәлил исемендәге колхоз таркалгач, янә дуңгызчылыкта эшли, янә шул тынгысыз хезмәтен дәвам итә. Ул карый торган группада ана дуңгызлар тәрбияләнә. Нәҗибулла Гобәйдуллович кулдашы Исхак Хәйруллин белән бергә алардан сәламәт үрчем алудан тыш, яшь дуңгыз балаларын исән-сау 2 айгача үстереп тапшырырга тиешләр. Терлекчеләр һәр ике бурычны намус белән үтәргә тырышалар. Сентябрь аенда, мәсәлән, алар дуңгызлардан 357 грамм тәүлеклек үсешкә ирештеләр. Ел башыннан 1 октябрьгәчә 496 баш дуңгыз баласы алдылар. Болар һәммәсе Нәҗибулла Гобәйдулловичның тырыш хезмәте нәтиҗәсе, әлбәттә.

Товарлыклы-дуңгызчылык фермасында эшләүче Хәмзә Хәлиуллович Рәхмәтуллин да урта мәктәпне тәмамлаганнан бирле язмышын терлекчелек белән бәйләгән кеше. Армиягә кадәр дә, аннан соң да дуңгызчылык фермасында эшләде, аннан нәкъ Нәҗибулла Гобәйдуллович кебек үк, бу тармак бетерелгәч, сарыкчылыкта хезмәт куйды. Инде менә өченче елын янә күнгән хезмәтендә. Ул ата дуңгызлар карый, дуңгызларны каплату эшен алып бара, шулай ук 2 айдан 4 айгача булган дуңгыз балаларын үстерә. Аның хезмәте турында да бары яхшы фикерләр генә ишетәсең хуҗалыкта. Сентябрь аенда ул дуңгыз балаларыннан 330 ар грамм тәүлеклек үсеш алды. Хәмзә Хәлиуллович группаны нигездә үзе генә карый, җәен исә улы Хәлил булыша. Гомумән, Рәхмәтуллиннар гаиләсендә балалар — ә алар бишәү — эшсөяр булып үсәләр. Бусы, мөгаен, этиләре һәм әниләре Нәгыймә үрнәгеннән дә киләдер. Нәгыймә мәктәп китапханәсендә китапханәче булса да җәй көннәрендә чөгендер участогы алып эшкәртә, балаларны да эшкә күндереп, хезмәттә тәрбияләргә тырыша.

Терлекчелекнең һәр тармагы — күп хезмәт, тырышлык сорый. Әнә савучылар Зәмзәмия Гыйманова, Сания Сафина да моны бик әйбәт аңлыйлар. Аларның һәр икесе колхоз савучылары ярышында әйдәп баралар. Зәмзәмия Гыймранова быелның 10 аенда үз группасындагы малларның һәркайсыннан 3004 килограмм сөт җитештерде, ә Сания Сафина группасында ул 2828 килограмм тәшкил итте. Октябрь аенда исә Рөкыя Камалетдинова барыннан да уздырды: 23 баш малдан ул 6273 килограмм тулай продукция җитештерде.

Шулай күмәк тырышлык белән хуҗалык елны уңышлы тәгалләргә тырыша.

**Г. САДЫЙКОВА,**
экономист.



Рәсемдәге 7 ир-егетнең җидесе дә — теге яки бу яктан терлекчелеккә катнашы булган кешеләр. Марат Хисмәтов — «Игенче» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы операторы, Фәрит Камалов 7 ел инде фермада лаборант булып эшли. Ә Мингалим Мәҗитов, Вәзир Садретдинов һәм Галимҗан Мингалимов исә — продукцияне җитештерүчеләр, алар — терлекчеләр. Җәйләрен малларны көтүлектә көтәләр, кышкы-көзге айларда савучыларга азык кертү, малларның асларын чистарту кебек эшләрдә булышалар. Ә инде Йосыф Вәлиуллин һәм Вазыйх Гомәровның биредә ни катнашы бар, алар бит шоферлар, диярсез. Савучыларны җәйге чорда җәйләүгә илтүче- алып кайтучылар — нәкъ алар. Шулай бердәм хезмәттә сезнең белән без ярата, нәниләр сөеп эчә торган файдалы продукция — сөт җитештерелә.

# Яктылыкка илткән юл

Һәркемнең дә йөрәге чыдый торган эш түгел бу. Кан исен хәтта кайбер ирләр дә күтәрә алмыйлар. Биредә исә нигездә хатын-кызлар. Эшләре дә нинди диген? Күтәрә, төшерә, гаять зур физик көч таләп итә торган.

Ит комбинатында терлекләрне чиратлап суялар. Көненә 200—250 баш сыер, 400 гә якын дуңгыз түшкәләре әзерлиләр. Түшләренә кадәр клеенка алъяпкыч таккан хатын-кызлар Анна Самохвалова белән Нурзия Фәйзуллина (ул Зәйнәп Мифтахетдинова чираттагы ялда булганга аның урынында эшләп тора) башта каннарны саркыталар, аннары станок ярдәмендә Татьяна Белозерова, Галина Кириллова тиреләрне салдыралар. Шул ук вакытта аларга үтә игътибарлы да булырга кирәк .Тирегә зыян килмәсен, сыйфаты сакланырга тиеш.

Цех эче шау-шулы, җылы пар бөркелеп тора. Конвейер белән килгән түшкәләрдән, башка хатын-кызлар белән бергә рәттән Галина Петровна Нестерюк (рәсемдә)



эчке әгъзаларны чыгарып, сортларга аерып тора. Аның куллары туктаусыз хәрәкәттә. Терлек сую цехында Нестерюк дистә ел эшли. Баштарак 80—100 сум хезмәт хакына да риза булып яшәгән.

— Ни хәл итәсең, эш сайлап йөрергә туры килмәде, шунда куйдылар, калдым, — ди ул үзе. — Бүген инде хезмәт хакым 600 сумга кадәр күтәрелде. Бик канәгать. Аннан, тагын бер нәрсә яхшы — бездә эш бер генә сменалы.

— Хәзер шартлар күпкә яхшырды, — дип сүзгә кушыла цех мастеры Любовь Николаевна Чернова да. — Элек бит монда бөтен төрле эшләр дә кул хезмәте белән башкарылды.

Шунда, искәрмәстән, ит комбинаты директоры Роман Саввич Чахмахчевның әйткән сүзләре хәтердә яңара: «Терлекләр сую базасы өчен бина булдырдык. Моңа хәтле малларны кышкы айларда шактый түбән температурада да урамда бастырып торганнар. Күпләп сую мөмкин булмаганлыктан, гел өзеклекләр туып торган. Хәзер мондый хәлгә юлыкмыйсың...»

Эш процессы бер-беренә бәйле булганга күрә, төрле сәбәпләр табып тукталып тору мөмкин түгел.

Производство калдыклары да әрәм-шәрәм ителми. Алардан он ясыйлар. Иләү өчен механик линияләр куелган. Аяк һәм башларны өтү цехы да хәзер күпкә үзгәргән. Бу бинада кайчандыр төтен чыгып, һава сулау мөмкинлеге булмаган. Бүген исә куәтле җилләткеч эшләп тора.

Пенсия яшендә булуына карамастан, өч дистә елдан артык хезмәт куючы һәм һаман да бу вахтаны дәвам итүче Нина Матвееваның чыдамлылыгына һәм түземлелегенә сокланырга гына кала. Ул бик зур теләк белән үз эше турында сөйли.

Тиреләрне тозлау цехында эшләүчеләргә барысына караганда да авырга туры килә. Аларда хәл ителәсе проблемалар да җитәрлек.

Канализация эшләми икән. Үтү юлларын тез тиңентен су баскан. Ә шуннан тиреләр төялгән арбаны тартып үтәргә кирәк. 1958 елдан бирле биредә мастер булып эшләүче Валентина Дмитриевна Ботрякова уфтанып куя:

— Кайчан гына яңа цехка күчәрбез инде, айһай кыен бит болай, — ди ул.

Цех ишек алдына бик күп итеп тозлы тиреләр өелгән. Аларның һәрберсе 30 килограмм, ә чылатылганнары исә 50 килограммга да җитә.

Проблемалар үз урынына, ә менә сәламәтлек өчен ялан кул белән тиреләрне тозлау искиткеч зыянлы. Нина Ивановна Костякованың бармакларында сөяк авыруы барлыкка килгән. Башкаларны да шундый ук язмыш көтә.

Нина Костякова белән Әлфия Вәлиева бу көнне өске катта тиреләр кабул итеп тордылар.

— Коточкыч, — ди Әлфия Вәлиева. — Биредә җилләткеч юк, астагы бөтен пар безгә килә.

Әйе, зарлану сүзләрен мездраль машина белән дуңгыз тиреләреннән май чыгарып торучы Валентина Ивановна Филимоновадан да ишетергә туры килде.

Эчәкләрне аеру цехы да автоматлаштырылмаган. Эшчеләргә аларны терлек сую урыныннан кул белән ташырга туры килә.

Директор Роман Саввич үзе дә биредәге җитешсезлекләрне яхшы белә:

— Яңа елга яңа цехлар ачылгач барысы да күпкә җиңеләячәк, — ди ул зур ышаныч белән. — Кафе-кибет ачарга җыенабыз. Анда пилмәннәр, пироглар, койкалар сатылачак. Эшчеләр өчен тагын 33 квартиралы йорт, сәламәтлек комплексы төзелеп килә. Яңа фин суыткычы сатып алдык. Бездә кадрларга мохтаҗлык гомумән юк.

Ит комбинаты бүгенге көндә менә шул рәвешчә яши. Ә аның киләчәгенә өметләр чиксез зур әле. Яктылыкка илтә ул юл.

**Г. РӘХИМОВА.**

# Депутатлар гаиләсе


Әкълимә Миндубаева «Татарстан» колхозының уңган терлекчеләреннән берсе санала. Дистә елга якын колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында эшли инде. Ел саен әйбәт күрсәткечләргә ирешеп килә. Тырышлыгын, уңганлыгын исәпкә алып үткән чакырылышта аны авыл Советы депутаты итеп сайлаганнар иде. Гаиләсе ишле булса да, җәмәгать эшендә дә актив катнашып килде.

Миндубаевларны, гомумән, авылда эшчән гаилә саныйлар, башкаларга үрнәк итеп куялар. Ире Җәүдәт тә авылдашлары арасында абруйлы. Соңгы сайлаулар вакытында инде ирен — Миндубаевны колхоздашлары авыл Советына депутат итеп сайладылар. Инде ул авылдашлары наказын үтәү мәшәкатьләре белән мәшгуль.

Ә Әкълимә исә элеккечә фермада хезмәтен дәвам итә. Тәҗрибәле савучы һаман әйдәп баручылар сафында. Агымдагы елның ун аенда үз группасындагы һәр сыердан уртача 3283 килограмм сөт савып алуны тәэмин итте. Бу — уртача колхоз күрсәткеченнән күпкә югары нәтиҗә.

**Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.**

# Кан кардәшлек



Бармы безнең көннәрдә кан кардәшлек? Әле ничек кенә! Берәүнең гомерен саклап калу, сәламәтлеген кайтару өчен икенче кешенең канын салу кебек изге күренешне тагын ничек атап булыр иде икән.

Районыбызның байтак кешеләре — донорлар. Шуларның бик күбесе СССР һәм РСФСРның Почетлы донорлары исемен йөртәләр. Хәтта канының күләмен 30—40 литрга җиткерүче донорлар да бар.

Тик әлегә барыбер донорлар мәсьәләсендә хәл борчулы тора. Хәтта мөмкинлекләре булган кешеләр туганнарына, якыннарына да үз канын бирүне кирәк санамыйлар. Нәрсә булды безгә? Киләчәктә ничек яшәрбез? Әлегә бернәрсә ачык: донорларның абруен күтәрергә кирәк. Матди кызыксындыру, почетлы донорлар өчен төрле льготалар булдыру, әйтик, туклануны яхшырту һәм башкалар ярдәмендә донорлар санын арттырырга мөмкинлек бар. Алар үзләренең кирәклеген тоеп яшәргә тиеш.

Газета укучыларга СССРның Почетлы доноры Александра Михайловна Колотухина белән бер дусларча очрашу турында сөйлисем килә.

Мин аңа текәлдем дә, аның тере ягымлы күзләре, сөйкемле елмаюыннан күземне ала алмыйм. Әйтерсең лә, бу хатынның йөзеннән сәламәтлек үзе бәреп тора. Ә бит ул яшь түгел инде, аның алты онычы. Бөтен әбиләр кебек ул да алар турында кайгырта. Өстәвенә бабай да авырып киткән, тагын йөрәк әрнүле. Ә минем янга үзенең чирле апасы турында сөйләшергә килгән. Сүз арасында мин искәрмәстән генә сорап куйдым:

— Сез бик күп каныгызны бирдегез. Донор буларак берәр истә калырлык хәл булмадымы? — дидем. Һәм ул очкынланып сөйләп китте.

— Әлбәттә, аларны һич онытырлык түгел. Бердәнбер көнне Елаур авылыннан посылка килеп төште. Аптырадым, туганнар, танышлар юк анда. Ачып карасам, анда бал да, бик матур яулык иде. Ә хатында «Исәнме, минем кан-кардәшем! Сезгә Петр Законов яза. Сез бит минем гомеремне саклап калган кеше». Һәм шул чакта исемә төшердем: бер ир-атка турыдан-туры канымны биргән идем. Хатында ул миңа рәхмәтен белдергән.

Тагын шундый бер очрак булды. Ничектер башкарма комитетына кергән идем: бер хатын минем фамилиям ничеклеген сорый. Шуннан ул миңа: «Бик зур рәхмәт сезгә! Энем өчен рәхмәт. Сез аның тормышын саклап калгансыз», — ди. «Мин белмим бит аны», — дигән идем. Ә ул янга таба күрсәтеп: «Менә бит ул терелеп чыкты», — ди. Ир-ат тыйнак кына баскан килеш миңа елмайды да кулын сузды. «Бөтен күңелемнән рәхмәт сезгә».

Урман хуҗалыгында яшәүче бер малай белән булган очрак хәтердә әле. Ул ат астында калып бавырын җәрәхәтләгән иде. Аңа да минем каным ярдәм итте. Мин 1968 елдан түләүле донорлыктан башладым. Аннан соң барысы кебек үк түләүле ,бушлай донорлыкта катнаштым. Өстәвенә, машина төзү заводының Кызыл Хач җәмгыятенең беренче оешмасы рәисе булдым. Минем белән эшләүчеләр арасында да донорлар байтак иде, оешмабыз да яхшы исәптә булды.

Менә ул шуларны сөйләде. Үземнең фикерләремне тәмамлаганда, бөтен донорларга — кеше хәленә керә белүче, бөек хисле кешеләргә рәхмәтемне белдерәм һәм 18-еннән 20 нче ноябрьгә кадәр шәһәрдә, аннан соң авылларда донорлык көннәре башлануын хәбәр итәм.

**В. БАТРАКОВА,**
Кызыл Хач җәмгыятенең район комитеты рәисе.

---

## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

### Аңа... 943 яшь

Караганда шәһәрендә планетабызның иң өлкән кешесе Екатерина Кондратьевна Шнайдер яши. Ул яхшы гына эшләп йөри. Күптән түгел аңа... 943 яшь тулды.

Шнайдерның туу турындагы таныклыгына 1048 ел датасы куелган. Авыл Советы мөһере дә сугылган.


Екатерина туу датасын дөресләп яздыру өчен Ивановск поселок Советына мөрәҗәгать итә. Әмма төптәге регистрация китабында да шул ук дата булу сәбәпле, аңа тагын да югары органнарга мөрәҗәгать итәргә кушалар.

### Сезгә ничәнче размер?

Удмуртиянең Можгинск районындагы Юдрук авылында яшәүче пенсионер И. Главатских оныткан һөнәрен 50 ел узгач яңадан исенә төшергән.

Күптән түгел ул үзе үргән юкә чабаталары белән базарга чыкты. Авыл остасының товарын алып бетергәннәр. Дөрес, чабата сатып алыр өчен әлегә дилбегә буе чират юк. Әмма 80 яшьлек пенсионерның өмете зурдан. Чөнки, ни әйтсәң дә, Можга шәһәрендә генә түгел, республика аяк киемнәре кибетләренең киштәләре дә буш ич. Һәм, күренгәнчә, якын арада җайга салынырга да ошамаган. Ә алда — җәй. Чабата өчен менә дигән сезон...

**«Труд» газетасыннан.**



Колхоз җыелышында. Тәмәке тартып алырга чыктылар, ә проблемалар калды.

## Тиңемне эзлим

Мин үзем Үрнәк авылында яшим. Йортым, хуҗалыгым, мунчам һәм башка корылмаларым бар. Үземә турылыклы иптәш эзлим. Миңа 63 яшь, буем 176 сантиметр. 50—67 яшьләр чамасындагы хатын-кыз белән танышырга телим. Әгәр минем белән тормыш корырга теләүчеләр булса, «Дуслык» район газетасына хәбәр итсен, ә минем дә, синең дә адресың, исем-фамилияңне алар әйтәчәк.

---




Кизләү авылында яшәүче кадерле әниебез Мәйсәрә Хәлиулла кызы Бильданованы 55 яшь тулган көне белән кайнар котлыйбыз.

Әниебезгә бәхет, шатлык, кояштай озын гомер, корычтай нык сәламәтлек телибез.

Мәңге шат яшә, әниебез.

**КЫЗЛАРЫ, КИЯҮЛӘРЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

x x x

Зирекле авылында яшәүче сөекле әниебез Сәкинә Шәрифулла кызы Гобәйдуллинага 62 яшь. Без аны туган көне белән кайнар котлыйбыз, озын гомер, шат көннәр, нык сәламәтлек телибез.

**КЫЗЫ, КИЯВЕ, ОНЫГЫ.**

---

## „Укытучы" кооперативы

читтән торып уку өчен пособие тәкъдим итә. Анда типик темаларга үрнәк-сочинение, шулай ук имтиханнарга тәкъдимнәр һәм киңәшләр тупланган.

Югары уку йортларына керүчеләр өчен өч пособие: 1. Нигездә программ әсәрләр буенча сочинение. 2. Биредә күбесенчә хәзерге заман әдәбиятына сочинениеләр: «Арбат балалары», «Плаха», «Тормыш һәм язмыш», «Ак киемнәр», В. Пикуль романнары һәм тагы башкалар. 3. Болары әдәбият яңалыкларына күзәтүләр, үзгәртеп кору, яшьләр, экология, әхлак һәм башка темаларга сочинениеләр.

Мәктәптә укучылар өчен дүрт пособие: берсе гомуми 9—11 класслар өчен. Анда мәктәп программасы буенча сочинениеләр җыелган һәм өч аерым сочинение 9, 10, 11 класслар өчен. Һәр өч пособиедә дә шушы класслар өйрәнә торган төп әсәрләр буенча сочинениеләр, шулай ук ирекле яки класстан тыш темага сочинениеләр тупланган. Һәр пособиедә 12—14 тулы сочинение. Темалар кабатланмый.

Бер пособиенең бәясе — 25 сум. Акчаны почтадан пособиене алганда түләргә. Заказларны түбәндәге адреска открыткаларга язып салыгыз: 400059, Волгоград, почтовое отделение, 59а, кооператив «Учитель». Телефон: 42—41—69.

Мәктәпләр һәм оешмалар пособиене акчаны кулдан түләмичә (безналичный расчет) Волгоград шәһәре, «Волгопромбанкы»ның 1461821 нче Киров коммерция бүлеге, МФО 261935, кооператив «Учитель» счетына күчерү юлы белән алалар. Бер үк вакытта «Укытучы» кооперативы адресына (алдан язылды) пособие сорап заявка җибәрергә кирәк. Түләү поручениесендә алучының төгәл адресы һәм заказ бирелгән брошюраның номеры булырга тиеш.

x x x

Октябрь райбашкарма комитетының күп тармаклы производство предприятиесенә ГАЗ-53 машинасында эшләү өчен шофер кирәк.

x x x

Норлат-Октябрь ДОСААФ район комитеты (СТК) түбәндәге категорияләргә машина йөртү таныклыгы алу өчен укучылар кабул итә:

1. «А» категориясе — мотоциклчы, уку срогы 2,5 ай.
2. «В» категориясе — автомобиль сөючеләр, уку срогы — 3,5 ай.
3. «ВС» категориясе — шофер-профессионал, уку срогы — — 5,5 ай.
4. «Д» категориясе — автобус йөртүче.
5. «Е» категориясе — ярымтаккычта эшләүче.

Белешмәләр өчен Норлат шәһәре, 60 лет Октября урамы, 16 йортта урнашкан ДОСААФның район комитетына мөрәҗәгать итәргә. Телефон: 2—25—80.

x x x

Яңа микрорайондагы ике катлы йортта бөтен уңайлыклары булган бер бүлмәле фатир (1 нче катта, подвалы, өй яны участогы бар) ике бүлмәлегә алмаштырыла. Артык бүлмә өчен хак килешү нигезендә түләнә.

Белешергә теләүче Промышленная урамы, 4 йорт, 2 фатирга мөрәҗәгать итсен.

### ХУҖАСЫ КЕМ?

Норлатның хуҗалык товарлары кибетендә акча янчыгы табылды. Югалтучы шушы кибет сатучыларына мөрәҗәгать итсен иде.

x x x

Шәһәрнең сәүдә мәйданында талоннар белән акча янчыгы таптым. Югалтучы 40 лет Октября урамы, 1а йорты, 13 фатирда яшәүче Казаковларга мөрәҗәгать итсен.

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.**

**Газетада язмалары басылган авторларының фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**

**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир — 2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары — 2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары — 2—15—63, социаль-экономика бүлеге — 2—22—51, җаваплы секретарь — 2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия — 2—18—67.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.**

**Күләме — 1 басма табак. Заказ 137. Тираж 3413.**